ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2022 елның 18 феврале.

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелде, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 22 декабрендәге 114-РС номерлы карары белән билгеләнде.

Урта Девятово авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2021 елның 22 декабрендәге 114-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2021 елның 27 декабрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;
2. 2021 елның 22 декабрендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы» («Камская новь») газетасында;
3. 2021 елның 27 декабрендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 гыйнварындагы 35/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

Ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр 2022 елның 11 гыйнварында басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2021 елның 12 гыйнварында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2021 елның 12 гыйнварында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2021 елның 13 гыйнварында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында.

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Башкарма комитеты.

Рәислек итүче: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.- Карсалов Алексей Петрович.

Ачык тыңлаулар секретаре: - Чумарова Ооьга Николаевна - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге башлыгы.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2022 елның«17»февралендә Урта Девятово авыл җирлегенең Генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 21 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Халык тыңлауларын үткән дип танырга;
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авыл җирлегенең Генераль планы проектын, 2022 елның«17»февралендәге ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре _________________________Чумарова О.Н.